СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 14 » ноябрь 2023 ел** **№ 247**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру буенча заказчы - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты;

2.2.Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына аукцион оештыручы- Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге .

3. «Арча муниципаль районында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына сатулар үткәрү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 07 декабрендәге 1199 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 04 сентябрендәге 689 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга (2012 елның 12 апрелендәге 431 номерлы үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында

(http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев